ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТОЙГУҖА АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

---

КАРАР

«28» ноябрь 2023 ел № 2

2024 елда
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлегенең Тойгуҗа авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

- скважина өчен су насосы сатып алу;
- сууткәргеч бикне һәм янгын гидрантларын комплектта сатып алу;
- сууткәргеч бикне һәм янгын гидрантлары урнаштыру;
- авыл җирлеге территориясендә үлән чабу;
- юлларны кардан чистарту;
- узган елларның калдыкларын янгын гидрантларын урнаштыруга җибәрергә».

3. . Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Тойгуҗа авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А.Сафин